Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең Иске Көшкәт авылы торак пунктының ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

06 декабрь 2021 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 ел, 28 июль, 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең Иске Көшкәт авылында гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең Иске Көшкәт авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булмаган һәр кешедән, түбән керемле (80 яшькә җиткән) ялгыз өлкән яштәге пенсионерлардан, онкология авыруларыннан, Россия Армиясендә үзара салым суммасының 90% күләмендә ташламалар бирүдән тыш, 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү каралган.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Иске Көшкәт авылында җиһазлар сатып алу белән спорт мәйданчыгы урнаштыру;
- Иске Көшкәт авылына керү юлы белән чишмә чистарту һәм ремонтлау.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә (baltasi.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.)

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Балтач муниципаль районы
Яңгул авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Габдрахманов